**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с.Сокуры,
ул. Державина, д.12 а
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ** *РАЙОНЫ* **СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Державино урамы, 12 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**№ 32** **«07» октября 2019**

# РЕШЕНИЕ

# КАРАР

## "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм «муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 21.07.2005 ел, №97-ФЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасының 28.07.2004 ел, №45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Законы нигезендә Сокуры авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:
1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокурово авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Камская новь» («Кама ягы») район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә): http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башлыгы Новиков Анатолий Александровичка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Сокуры авыл җирлеге**

**Башлыгы, Совет рәисе** **А.А. Новиков**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Сокуры авыл җирлеге**
**Советының 2019 елның 7 октябрендәге**
**32 номерлы карарына Кушымта**

## “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр”

23 статьяның 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «9. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыграгы катнашуда вәкаләтле, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены этаплап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмый торган вакыт эчендә үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый.».